ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.04.2023 п.г.т.Алексеевское № 125

**Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр бирүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен техник чараларының запас частьләренең, инструментларның һәм кирәк-яракларның резервын булдыру, саклау һәм куллану тәртибе турында**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге № 68-ФЗ, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 декабрендәге № 28-ФЗ федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.04.2000 ел, № 379 «Матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын туплау, саклау һәм гражданнар оборонасы максатларында куллану турында», 25.07.2020 ел, № 1119 «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнарының матди ресурслары резервларын булдыру, алардан файдалану һәм тулыландыру кагыйдәләрен раслау турында», Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 19.02.2021 ел, №1 «Халыкка хәбәр итү системаларын булдыру һәм реконструкцияләү буенча методик тәкъдимнәр» карарларына туры китереп.

**карар бирәм:**

1.Расларга:

1.1. Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр бирүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен техник чараларының запас частьләренең, инструментларның һәм кирәк-яракларның резервын булдыру, саклау һәм куллану тәртибен (1 нче кушымта);

1.2. Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен техник хәбәр итү чаралары резервы номенклатурасы (2 нче кушымта);

1.3. Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен запас частьләр, инструментлар һәм кирәк-яракларны тулыландыруга үрнәк гариза (3 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазифаларын башкаручы** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.04.2023 ел, № 125
карарына 1 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр бирүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен техник чараларның запас частьләренең, инструментларның һәм кирәк-яракларның резервын булдыру, саклау һәм куллану тәртибе**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр бирүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен техник чараларының запас частьләренең, инструментларның һәм кирәк-яракларның резервын булдыру, саклау һәм куллану тәртибе (алга таба - Тәртип) «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге № 68-ФЗ, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге №28-ФЗ Федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 27.04.2000 ел, № 379 «Матди-техник запасларны азык-төлек, медицина һәм башка чаралар туплау, саклау һәм гражданнар оборонасы максатларында куллану турында», 25.07.2020 ел, № 1119 «Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнарының матди ресурслары резервларын булдыру, алардан файдалану һәм тулыландыру кагыйдәләрен раслау турында», Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 19.02.2021 ел, №1 «Халыкка хәбәр итү системаларын булдыру һәм реконструкцияләү буенча методик тәкъдимнәр» карарларына туры китереп төзелгән,

1.2. Әлеге Тәртиптә түбәндәге кыскартулар кулланыла:

- МСО - халыкка хәбәр итүнең үзәкләштерелгән муниципаль автоматлаштырылган системасы;
- РАСЦО - халыкка хәбәр итүнең үзәкләштерелгән төбәк автоматлаштырылган системасы;
- ТСО - техник хәбәр итү чаралары;
- ЗИП - запас өлешләр, кораллар һәм кирәк-яраклар;
- ЧС – гадәттән тыш хәл.

1.3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы өчен ТСО резервы (алга таба - ТСО резервы) хәбәр итү системаларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү өчен билгеләнгән, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының МСО ның сафтан чыккан һәм торгызуга бирешми торган составлы элементларын һәм РАСЦО ның составлы өлешен вакытында алыштыру өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы МСО яуламаган территорияләрдә һәм ЧС зоналарында халыкны мөмкин кадәр күбрәк колачлауны тәэмин итү өчен билгеләнгән.

1.4. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы МСО һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә эшләүче РАСЦО состав өлеше өчен ЗИП резервы (алга таба - ЗИП резервы) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы МСО состав элементларының һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә эшләүче РАСЦО состав өлешенең сафтан чыккан һәм торгызылырга тиешле состав элементларының үз вакытында эшләвен торгызу өчен билгеләнгән.

## 2.ТСО һәм ЗИП резервларын булдыру һәм күләмнәрен билгеләү тәртибе

2.1. ТСО һәм ЗИП резервы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан алдан ук булдырыла.

2.2. ТСО һәм ЗИП резервын сатып алу Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслана.

2.3. ТСО резервы номенклатурасы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

2.4. ТСО ны резервлау Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы МСОда аның гомуми саныннан ким дигәндә 5- 10% җиһаз берәмлеге исәбеннән башкарыла.

2.5. ЗИП резервы номенклатурасы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы МСО эксплуатация-техник документациясеннән чыгып, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы МСО эксплуатация-техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларның гаризаларына яраштлы рәвештә раслана.

## 3.ТСО һәм ЗИП резервларын бирү һәм тулыландыру тәртибе

3.1. ТСО һәм ЗИП резервы Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе боерыгы буенча бирелә. ТСО һәм ЗИП резервы аларның яңартылуы (билгеләнгән саклау срокларына җиткәндә) яки Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының эшләми торган МСО җиһазларын алыштыру белән бәйле рәвештә бирелә.

3.2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карамагында ТСО һәм ЗИП резервларын бирү турында максатчан билгеләнеше һәм ТСО һәм ЗИП резервларын тулыландыру чыганагы күрсәтелә.

3.3. ТСО һәм ЗИПның сарыф ителгән резервын тулыландыру Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

3.4. ТСО һәм ЗИП резервының тулыландырыла торган күләме ТСО һәм ЗИП резервының сарыф ителгән күләменә туры килергә тиеш.

## 4.ТСО һәм ЗИП резервларын саклау тәртибе

4.1. ТСО һәм ЗИП резервларын саклау ТСО резервының яки ЗИП резервының конкрет төренең эксплуатация-техник документациясе таләпләренә ярашлы рәвештә саклау өчен билгеләнгән объектларда башкарыла.

## 5.ТСО һәм ЗИП резервларын булдыруны, саклауны, тулыландыруны куллануны тәэмин итү буенча эшчәнлекне оештыру

5.1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты ТСО һәм ЗИП резервларын булдыруны, саклауны, куллануны һәм тулыландыруны тәэмин итү эшчәнлеген оештыру өчен:

- ТСО һәм ЗИП резервы номенклатурасы һәм күләме буенча тәкъдимнәр эшли;
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы МСО эксплуатация-техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалардан ЗИП резервын тулыландыруга гаризаларны вакытында алуны контрольдә тота;
- ТСО һәм ЗИП резервын тулыландыруга (сатып алуга), саклауга һәм тотуга чыгымнар күләмен билгели һәм чираттагы финанс елына акчалата средстволар лимитларын раслау буенча карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына тиешле финанс-икътисади нигезләмәне тәкъдим итә;
- ТСО һәм ЗИП резервының саклау урыннарын билгели, алар саклау шартлары таләпләренә һәм ТСО һәм ЗИП резервларын гадәттән тыш хәлләр зоналарына җиткерү мөмкинлегенә җавап бирә;
- расланган номенклатурага ярашлы рәвештә ТСО һәм ЗИП резервларын тулыландыру (яңарту) өчен җиһазлар сатып ала;
- ТСО һәм ЗИП резервларын саклау, яңарту, алыштыру, хезмәт күрсәтүне оештыра;
- гадәттән тыш хәлләр районнарына ТСО һәм ЗИП резервларын китерүне оештыра;
- ТСО һәм ЗИП резервы составына керүче җиһазлар белән операцияләр (куллану, тулыландыру, яңарту) буенча исәп-хисап һәм хисап алып бара;
- ТСО һәм ЗИП резервларын куллануга даими әзерлектә тотуны тәэмин итә;
- ТСО һәм ЗИП резервының булу-булмавын, сыйфатлы торышын, саклау шартларын үтәвен һәм аларны саклау буенча чараларны үтәвен контрольдә тота.

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.04.2023 ел, № 125
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен техник хәбәр итү чаралары резервы номенклатурасы**

| т/б № | Халыкка хәбәр итүнең техник чаралары резервы номенклатурасы (исеме) | Үл. бер. | Резерв күләме (саны) | Билгеләнеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| **МСО** | | | | | |
| 1 | Автоматлаштырылган эш урыны | данә | 1 | Хәбәр итүне башлау һәм мониторинглау | |
| 2 | УЗС2-1А27Н оператив дежурның хәбәр итү блогы | данә | 2 | Сигнал кабул итү җайланмасы | |
| 3 | Инверторлы бензин генераторы | данә | 8 | Электр сиренасының энергияне сүндергәндә эшләвен саклау | |
| 4 | СиБи элемтә радиостанциясе | данә | 2 | Сигнал кабул итү җайланмасы | |
| **РАСЦО** | | | | | |
| 1 | РСУ-300 | данә | 3 | Соңгы хәбәр итү җайланмасы | |
| **Йөртелә торган техник хәбәр итү чаралары** | | | | | |
| 1 | Рупорлы тавышкөчәйткеч | данә | 2 | Стационар хәбәр итү чаралары белән капланмаган территорияләрдә халыкны хәбәр итүне оештыру | |

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
11.04.2023 ел, № 125
карарына 3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы халкына үзәкләштерелгән хәбәр итүнең муниципаль автоматлаштырылган системасы өчен запас частьләр, инструментлар һәм кирәк-яракларны тулыландыруга үрнәк гариза**

| т/б № | ЗИП исеме | Торгызу өчен ЗИП кирәк булган җиһазның исеме | Кирәк булган ЗИП саны | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Вазифа Имза Ф.И.А.

**(гариза бирүче оешма җитәкчесе)**

«___»__________20__ел